# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Речное авыл торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2025 елның 27 октябреннән** **№ 4**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Речное авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Речное авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан,МХО да катнашучылар һәм сугыш хәрәкәтләре инвалидларыннан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- су белән тәэмин итү һәм агынты сулар агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Сахаровка авыл җирлеге Башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә ».

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен 10 көн эчендә Сахаровка авыл җирлегенең Речное авылы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Сахаровка авыл җирлеге
1 нче сайлау округы депутаты Н.И. Леденцов

(имза) (имза расшифровкасы)